

Россиядә зур сынаулар узган чыгарылыш класс укучыларынын туган мәктәпләре, яраткан укытучылары белән саубуллашыр коннәре 28 һәм 29 июньдә узды. Мәктәпләрдән 2 млн 300 меннән артык тугыз һәм унбер сыйныф укучысы чыгарыла. Быел аларны 1,2 меннән артык югары йорты һәм 3,8 мен колледж котә. Шул исәптән Мордовиянен мәктәпләрен оч менгә якын унберлеләр (2762) тәмамлады. Алар арасында 16 чыгарылыш 11 сыйныф укучысы ЕГЭларын 100 баллга тапшырган, ә 641 укучы мәктәпне “алтын” һәм “комеш” медальләре белән тәмамлаган.      28 июньдә Саранск, Рузаевка, Ковылкино, Инсар һәм башка шәһәр чыгарылыш сыйныф укучылары тантаналы рәвештә һәркайсы аттестатлар - олы тормышка юлламалар алды. Аларнын шатлыгын әти-әниләре, якыннары, дуслары да бvлеште. Кvлмәк-туфлиларнын ин матурын, ин кыйммәтлесен кигән кичәге укучылар чәчтараштa барып прическа ясатып тагы да матур кvренделәр. Мәктәпләрдә, шәһәр паркларында ял итv программасын vтәгәч, кайбер мәктәп сыйныфлылары мәжлесләрен я кафеда, я ресторанда vткәрделәр. Билгеле инде, профессиональ фотограф белән видеооператор да читтә калмый. Монын топ оештыручылары - әти-әниләр комитеты. Балалары очен бар момкинчелекләрдән кулланганнар.
Рузаевка шәһәрендә 221 чыгарылыш сыйныф укучысы Балда катнашкан. Шул исәптән Татар Пешлә мәктәбенен 6 укучысы да.
Ләмберәнен икенче мәктәбен 11 чыгарылыш сыйныф укучысы тәмамлаган. Алар арасында “алтын” һәм “комеш”, ягъни I һәм II дәрәжә медальләре белән бvләкләнгәннәр байтак. “Алтын”га лаек-лылар: Аюпова Карина Рустам кызы, Богданов Абдулмалик Дамир улы, Сяфукова Ангелина Олеговна, Мироненко Анна Сергеевна. “Комеш” медаль иясе Салихов Амир Ильдар улы. Тантаналы кичәләре Ләмберәнен “Алмаз” мәдәни-спорт vзәгендә vткән.



Бар гадилекне, сафлыкны, ихласлыкны чагылдырган авыл мәктәбе кичәләре кvбебезгә якын һәм истәлекле. Мәсәлән, Ромодан районы Белозерье урта мәктәбе директоры Эльвира Идрис кызы Киреева чыгарылыш укучылары турында: “Быел 37 тугызынчы сыйныф һәм самообразование программасы буенча алты 11 сыйныф укучысын олы тормыш юлына чыгарып жибәрдек. Тугызлыларда тантаналы чыгарылыш кичәсе vтте, ә унберләргә аттестат тапшыру гына иде”.
“Торбеево районы Жуковский урта мәктәбе филиалы булган Татар Юнкие топ мәктәбендә чыгарылыш кичәсе 29 июньдә vтте. Барлыгы 8 укучыбыз, - ди мәктәп житәкчесе Тәнзилә Әхмәт кызы Утешева.- Бу конне бик матур әдәби-музыкаль кичә узды“.
“... Артта авыр сынаулар, имтиханнар. Һәм менә кунаклар белән бергә: укытучылар, әти-әниләр, дуслар, яраткан чыгарылыш укучыларын, матур, vсеп житкән, тәрбияле,

сәләтле егетләрне һәм нәфис кызларны озаттылар.
Тугызынчы сыйныф укучыларына балачак белән хушлашырга, беренче нәтиҗәләр ясарга, безнен мәктәптә vткәргән тугыз шатлык-лы бай елларын искә тошерергә вакыт житте. Чыгарылыш кичәсе кvнелле дә, кvнелсез дә булды! Укучылар мәктәп администрациясенә, сыйныф житәкчесенә, кадерле педагогларына сабырлыклары, авыр хезмәтләре, игелекләре, оптимизмнары һәм мәхәббәтләре очен рәхмәт белдерделәр. Әлбәттә, vзләре дә укудагы унышлары очен Рәхмәтләр һәм котлаулар алдылар.
9 нчы сыйныф укучыларын һәм ата-аналарын топ мәктәпне тәмамлаулары белән ихластан котлыйбыз! Жәй коне бик яхшы ял итәргә, коч, якты тәэсирләр тупларга һәм теләкләренә ирешергә телибез! – дип фикерләре белән уртак-лашты Кадошкино районы Большие Поляны топ мәктәбе директоры Светлана Наиль кызы Кильдеева.
Бу яна олы тормыш алдында торган яшь кешеләр очен махсус даталар. Безнен һәрберебез мәктәпне тәмамлауны хәтерли, бу vзенчәлекле кон, мәктәп коридорлары һәм сыйныфлар артта калды. Кvпләребез очен чыгарылыш кичәсе беренче зур вакыйга булды, анда без vзебезне ике донья чигендә хис иттек: балалар тvгел, ә әле олылар да тvгел. Бу кон кайгысыз балачак белән хушлашуны һәм яна башлангычлар һәм момкинлекләр юнәлешендә адымны символлаштыра.

**Наилә НАСЫРОВА**